ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 034 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район башлыгының
10.12.2010 елның 10 декабрендәге
076 нчы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 октябрендәге 1374 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре турында» 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698т номерлы Указы нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә наркотик матдәләр, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору, халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау максатларында, муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау максатларында карар бирәм:

1. Мамадыш муниципаль районында наркотикларга каршы комиссиянең яңа составын расларга (килешү буенча) (1 нче кушымта).

2. Муниципаль район башлыгының 10.12.2010 ел, № 076 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районында наркотикларга каршы көрәш комиссиясе турындагы нигезләмәгә (алга таба нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- Нигезләмәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Комиссия утырышы кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булган очракта, комиссия рәисе карары буенча чираттан тыш комиссия утырышлары үткәрелә»;
- Нигезләмәнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә : «Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия беркетмәсенә рәислек итүче һәм комиссия секретаре карар кабул ителгән көнне кул куя. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала;
- 10 пунктка өстәргә:

1) Комиссия рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия Рәисе:

1)Комиссия эше белән җитәкчелек итә,

2) комиссия утырышларында рәислек итә,

000050

3) комиссия эшенеӊ сыйфаты, кабул ителә торган карарларның объективлыгы, эш нәтиҗәләре буенча документларны үз вакытында рәсмиләштерүнең үз вакытында башкарылуы өчен җавап бирә,

4) Комиссия утырышларын үткәрү датасын һәм вакытын билгели,

Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен башкара.

Комиссия секретаре:

1) комиссия утырышларын үткәрү графигын эшли,

2) комиссия әгъзаларына утырышларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итә,

3) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә.

Комиссия әгъзалары:

1) комиссия эшендә катнашалар,

2) каралган мәсьәлә буенча үз фикерләрен белдерәләр (Бу очракта аерым фикер язма формада),

3) кабул ителгән карарларның компетентлыгы өчен җавап бирәләр,

4) Комиссия секретарен җитди сәбәпләр аркасында утырышны үткәрү датасына кадәр кимендә ике көннән дә соңга калмыйча комиссия утырышында катнаша алмаулары турында кисәтәләр.

3.Муниципаль район башлыгының 10.12.2010 ел, № 076 карарының 1 п.белән расланган 1 нче кушымта (наркотикларга каршы комиссия составы), муниципаль район башлыгының 04.03.2015 ел, № 020; 21.10.2016 ел, № 100; 27.10.2017 ел, № 111; 21.03.2019 ел, № 030 карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
Башлыгы А.П. Иванов

муниципаль район
Башлыгы карарына
1 нче кушымта
№034 25.02.2021 ел

**Мамадыш муниципаль районында наркотикларга каршы көрәш комиссиясе (килешү буенча)**
**с о с т а в ы**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Иванов А.П. | - | Мамадыш муниципаль район башлыгы, комиссия рәисе |
| 2.Хуҗаҗанов М. Р. | - | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, рәис урынбасары, |
| 3.Юнысова Л.М. | - | Муниципаль район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге белгече, комиссия секретаре |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 4.Хафизов Ф.Э. | - | ТР Мамадыш районы прокуроры, юстиция киңәшчесе |
| 5.Усачев Л.Б. | - | РФ Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлеге начальнигы |
| 6.Шәйхетдинов Ф. М.- | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Мамадыш районындагы бүлегенең оператив эш буенча начальник урынбасары |
| 7.Бессонова К.В. | - | "Мамадыш РҮХ" ДАССОның табиб-наркологы |
| 8. Минникаева Е.Н. | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге консультанты |
| 9.Ханова С.Н. | - | «Татмедиа» АҖ филиалы «Мамадышинформ» директоры |
| 10.Габдрахманов И.Н. | - | «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| 11.Мөбәрәкшина Г. Р. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча Мамадыш районындагы бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе |
| 12.Егоров Н. Н. | - | Мамадыш политехник көллияте директоры |
| 13.Спиридонов С.П. | - | «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы |
| 14.Гарифуллин А.А. | - | ТР Мамадыш муниципаль районы «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ башлыгы |
| 15.Сергеев С. М. | - | ТР Мамадыш муниципаль районы Советының хокук мәсьәләләре буенча консультанты |

Муниципаль район Советы
Аппараты җитәкчесе В.Н. Фәизов